МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.04.2022 г.Казань № 254

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-аналарының берсе генә булса да инвалид һәм (яки) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-аналарының берсе генә булса да инвалид һәм (яки) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.02.2020 №70, 01.06.2020 №380, 09.10.2020 №718, 04.05.2021 №290, 17.11.2021 №846 кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр в.б. Р.Ф. Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
04.04.2022 №254 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-аналарының берсе генә булса да инвалид һәм (яки) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга.»;

Әлеге боерык белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-аналарының берсе генә булса да инвалид һәм (яки) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Административ регламент) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып Россия Федерациясе гражданнары, Татарстан

Республикасы территориясендә даими яши торган чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасыннан һәм гаиләнең мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасында билгеләнгән гаиләнең (гражданинның) мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзалары тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие (алга таба – айлык пособие) билгеләү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. «Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә. Үзәккә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.»

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮ ерактагы эш урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.

Кәгазь чыганактагы карар Үзәк бүлекчәсенең билгеләнгән үрнәктәге бланкында рәсмиләштерелә (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта). Нәтиҗәне кәгазьдә теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча.

### 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар барлык кирәкле документлар белән айлык пособие билгеләү турында гариза Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән көннән алып 14 эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Үзәк бүлекчәсе, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

### 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) банк яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет белешмәләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта) буенча айлык пособие билгеләү турында гариза;P481

2) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына керемнәрен раслый торган документлар, аларга түбәндәгеләр керә:

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында белешмә;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе җинаять-үтәү системасы учреждениеләре һәм органнары, таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган, Россия

Федерациясе законнарында билгеләнгән өстәмә түләүләр һәм азык-төлек тәэминаты күләме турында белешмә;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм күләме турында белешмә;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесе бәяләмәсе буенча аларның балалары читләр каравына мохтаҗ булса, ир белән хатынның хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда айлык пособие күләме турында белешмә;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүләре күләме турында белешмә;

3) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

4) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән гаилә теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

5) айлык пособие билгеләү өчен гариза мөрәҗәгать итүче вәкаләт биргән зат яки мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә бирелгән очракта, ышаныч кәгазе;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар):

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык, тарату өчен рөхсәт ителгән персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык булу;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре нотариус тарафыннан яисә документның оригиналын биргән орган (учреждение) тарафыннан таныкланмаган очракта, алар чын нөсхәләре белән бергә тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган

булырга тиеш.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек нигезендә алына торган документлар:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт органнары тарафыннан бирелә торган эшсезлек буенча пособие, стипендия, матди ярдәм күләме һәм аны алу турында;

пенсия һәм Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында;

айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

Социаль иминият фонды органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләр турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

күчемсез мөлкәт булуы турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы (алга таба – Россия Эчке эшләр министрлыгы) тарафыннан түләнә торган пенсияне алу һәм аның күләме турында;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы (алга таба – Россия Оборона министрлыгы) тарафыннан түләнә торган пенсияне алу һәм аның күләме турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булмавы турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Административ регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы;

Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве;

мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Булган белешмәләр һәм (яки) булган документлар нигезендә дәүләт хезмәте алуга хокук булмавы ачыклану аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары;

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер көн эчендә

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктальы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда

– бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында алынырга мөмкин.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексslы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:
күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;
Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары»;

3.3 пунктта:

икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүче бирүче айлык пособие билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктына туры китереп, документлар күчермәләрен теркәп тапшыра.»;

бишенче абзацта «Регламент» сүзен «Административ регламент» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «(2 нче кушымта)» сүзләрен «(әлеге Административ регламентка 2 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.1-3.4.2 пунктларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон формада вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында;

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт органнары тарафыннан бирелә торган эшсезлек буенча пособие, стипендия, матди ярдәм күләме һәм аны алу турында;

пенсия һәм Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында;

Социаль иминият фонды органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләр турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.

3.4.2. Айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында вәкаләтле органнарга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт органнары тарафыннан бирелә торган эшсезлек буенча пособие, стипендия, матди ярдәм күләме һәм аны алу турында;

пенсия һәм Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында;

айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

Социаль иминият фонды органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләр турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

күчемсез мөлкәт булуы турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

Россия Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме һәм аны алу турында;

Россия Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсияне алу һәм аның күләме турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурычлар булмавы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү

һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

3.5.1 пунктта:

беренче абзацта «Регламент» сүзен «Административ регламент» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Регламент» сүзен «Административ регламент» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Регламент» сүзен «Административ регламент» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп) мөрәҗәгать итүчегә айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Айлык пособиене билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, айлык пособиене билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар күчермәсен шәхсән тапшыру.»;

3.7.1 пунктның икенче абзацында «Регламент» сүзен «Административ регламент» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары»;

Административ регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм
аннан күбрәк баласы булган,
ата-анасының берсе яки икесе дә
инвалид бала булган һәм (яисә)
бер генә баласы булса да
инвалид булган гаилә
әгъзаларына айлык пособие
билгеләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә

_______________________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ___

«__» __________ 20__ ел.

Мин,______________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адрес: _______________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкиленең индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп, почта адресы)

эш итү нигезе:

_______________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Мөрәҗәгать итүченең СНИЛС _____________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) бер генә булса да баласы инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә

_______________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

айлык пособие (алга таба – айлык пособие) билгеләвегез турында сорыйм,

яши торган адрес: _______________________________________________

_______________________________________________________________,

(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

_______________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Гаилә составы:

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәт-ләре | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында булмавын раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

______________________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукында чикләнмәгән

________________ ______________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең имзасы, тулы имзасы)

Билгеләнгән айлык пособиене хисапка күчерү юлы белән түләвегез турында сорыйм

______________________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүче яисә аның законлы вәкиле тарафыннан кредит оешмасында социаль түләүләрне күчерү өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә ачылган счет реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм айлык пособие түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ______________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында да, риза:

әлеге адрес буенча язмача формада________________________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _______________________________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресына ____________________________________________

(электрон почта адресы)

__________________________________________________________ Үзәк бүлекчәсе аша

Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округында

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре)» дәүләт казна учреждениесендә минем айлык пособие алу хокукымны раслый торган белешмәләр булган очракта, мин мөрәҗәгать итмичә генә, миңа яңа чорга айлык пособие билгеләнүенә риза.

Мөрәҗәгать итүче:

_______________________________________________ ___________ «__» _________ 20__ ел.

Мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде

_______ 20__ ел. ____________________ ____________________________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

__________________________________________________________________________________.

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Гаризаның теркәлү №_____

Документлар саны ___ берәмлек, ___ биттә

Документлар кабул ителде _____________ ___________ ________________ ___________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Административ регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Административ регламентка 3-4 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
_______________________________________
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү турында карар

№_____ _________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) бер генә булса да баласы инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә айлык пособие билгеләргә ____________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес: ______________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

Түләү вакыты: ____ башлап _____ кадәр
Түләү ысулы: ______________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ______________________________ | ____________ |
| муниципаль районында (шәһәр округында) | (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы - булган очракта) | (имза) |

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ______________________________ | ____________ |
| муниципаль районында (шәһәр округында) | (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы - булган очракта) | (имза) |

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
шәхсән: _____________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
язма формада әлеге почта адресы буенча ___________________________;
______________________________________телефонына смс-хәбәр итеп,
(телефон номеры)

электрон документ формасында _________________ электрон почта адресы буенча.
(электрон почта адресы)

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләүдән баш тарту турында карар

№___ _________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) бер генә булса да баласы инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә
______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
айлык пособие билгеләүдән баш тартырга,
яши торган адресы: ______________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

Баш тарту сәбәбе: _______________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
__________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ муниципаль районында (шәһәр округында) | ______________________ (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы - булган очракта) | ____________ (имза) |

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече
______________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ муниципаль районында (шәһәр округында) | ______________________ (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы - булган очракта) | ____________ (имза) |

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):

шәхсән ______________________________,
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
почта адресы буенча язма формада ________________________
____________________________________телефонына смс-хәбәр итеп,
(телефон номеры)
әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында__________________
(электрон почта адресы);

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә
___________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
яши торган адрес: ______________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_____________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең шәхесен раслаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы,
_____________________________________________________________________,
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ___________________________________
_____________________________________________________________________,
18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән ______________________________________________________
(карар реквизитлары, бирелү датасы)

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки

икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында белдерү алуга риза

______________________________________________________________

(почта адресына язмача формада, электрон почта адресына электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп)

«__»________ 20__ ел. ______________________ ______________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

Административ регламентка белешмәлек кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта».